**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-15-99

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-15-99

«10» июнь 2019 ел №11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендә кабул ителгән 27 номерлы " Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, “ Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы “Актаныш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Актаныш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.1.6 Актаныш авыл җирлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендә кабул ителгән 27 номерлы “Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы нигезләмә”нең 1.6 пунктының 6 абзацына үзгәрешләр кертергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

- «1.6. авыллар арасында урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек төзү турында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр дә аның сайлау хокукына ия кешеләре саны 300 дән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;"

2. Әлеге карарны Актаныш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Э.Н.Фәттахов